СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ИВАНОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИВАНОВКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ | КАРАР

2022 елның «17» марты | № 3

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 декабрендәге 22 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка выл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 408-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Ивановка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Ивановка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 декабрендәге 22 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка выл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1 статьяны** түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:
«блокланган төзелеш йорты - башка торак йорт (башка торак йортлар) белән бер рәттә гомуми ян стенасы (гомуми як стеналары) белән блокланган һәм җир кишәрлегенә аерым чыгу урыны булган торак йорт.»;
**22 статьяның 2 өлешенең 6 абзацын** «,шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта;» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Лениногорск районы, Ивановка авылы, Үзәк урам, 27 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П. Бодряева